УДК 821.512.145

***Ж.А. Жакупов***

# КАЗАКЪ-ТАТАР РУХИ ЭЛЕМТӘСЕНЕҢ БЕР КҮРЕНЕШЕ ХАКЫНДА (Г. Ибраһимов һәм А. Байтурсынов)

В статье в сопоставительном плане показаны некоторые моменты биографии и творчества классика татарской литературы, общественного и государственного деятеля Г. Ибрагимова и казахского ученого-лингвиста, тюрколога и общественного деятеля А. Байтурсынова. Основной акцент делается на схожести взглядов и общественной позиции обозначенных личностей.

**Ключевые слова:** Галимджан Ибрагимов, Ахмет Байтурсынов, татарская литература начала XX века, проблема перевода письменности татар на латиницу.

2016 елда Казан китапханәсендә А. Байтурсыновның иҗаты хакында библиографик исемлекләргә әлегә кадәр кертелмәгән бер мәкалә табылды. Ул мәкалә Татарстанда гарәп графикасы белән татар телендә нәшер ителә торган «Безнең юл» журналында (1928 ел, 2 нче сан) дөнья күргән. Автор «Галимҗан Ибраһимов төрек-татар уйчысы (*фикер иясе*), төрек-татар белгече, төрек-татар язучысы» дип исемләнгән бу язмасын 1928 елның 24 гыйнварында Кызылордадан җибәргән була [Байтурсынов].

Мәкаләнең герое – галим, әйтеп үтелгән журналның редакторы, төрки халыклар бердәмлеге өчен көрәшүче әдип, безнең Алаш Орда татарларының фикердәше, төрки халыклар язмасын латин алфавитына күчерүгә каршы чыккан Әхмәт Байтурсыновны хуплаучы Галимҗан Ибраһимов. Әлеге хезмәттә казакъларның һәм башка төрки халыкларның рухи язмышы чагыштырып яктыртыла.

Кардәш халыкларның бу ике олуг вәкиле бер дәвердә яши. Шунысы мәгълүм, казакълар белән татарлар арасындагы бәйләнешнең башы борынгы төрки заманнарга ук барып тоташа. Ә менә бу ике халыкның да рухи яңарышы 1905 елдан – Россиядәге буржуаз-демократик инкыйлаблар чорыннан башлана. Мәгълүм булганча, бу вакытта төркичелек идеологиясе көчәя. Нәкъ менә шул тарихи вакыйгалар белән бәйле елларда Әхмәт Байтурсынов белән Галимҗан Ибраһимов шәхесләре фикри яктан башка замандашларыннан аерылып торалар. Аларның тарихи аренага чыгарган юллары да бер-берсенә охшаш. Инде шул юлларны чагыштырып карыйк.

А. Байтурсынов (1873) та, Г. Ибраһимов (1887) та авыл җирендә туганнар.

Икесе дә дини мәктәпләрдә башлангыч белем алганнар.

Аннан соң икесе дә рус мәктәбендә укыйлар: А. Байтурсынов 2 сыйныфлы рус-казакъ мәктәбен 1891 елда тәмамлап,

Оренбургтагы 4 еллык мәктәпкә укырга керә; Г. Ибраһимов исә рус мәктәбеннән соң «Галия» мәдрәсәсендә белем ала.

Хезмәт юлларын икесе дә укытучы булып башлыйлар: Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә, 1920–1924 елларда мәгариф системасында эшли; А. Байтурсынов исә башта авыл мәктәбендә укыта, 1921–1925 елларда Оренбургта, 1926–1928 елларда Ташкентта казакъ әдәбияты һәм теле, шулай ук мәдәният тарихы буенча белем бирә. 1928 елдан Алматыдагы Казакъ дәүләт techинституты ректоры тәкъдиме белән профессор дәрәҗәсендә хезмәт куя.

Әдипләрнең икесе дә журналистлар һәм мөхәррирләр буларак та танылалар: Россиядәге Февраль инкыйлабыннан соң Г. Ибраһимов, Сәйфи Фәйзи белән бергә, «Ирек» газетасы чыгара, сентябрьдән «Безнең юл», «Мәгариф» журналларын һәм «Чулпан» газетасын редакцияли; А. Байтурсынов 1913–1918 елларда үзенең иң ышанычлы дуслары А. Бакыйхан һәм М. Дулатов белән «Казакъ» дип исемләнгән беренче гомуммилли газетаны чыгара.

Галимнәр икесе дә фәнни процесслар белән идарә итәләр: Г. Ибраһимов 1919–1920 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, 1925–1927 елларда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәкне җитәкли, В.И. Ленин хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итү комиссиясе рәисе урынбасары һ.б. [Большая советская энциклопедия, т. 9, с. 621]; А. Байтурсынов 1919–1921 елларда Казакъстанда Халык мәгарифе комиссары, 1922 елда Край мәгариф комиссариаты каршындагы Академүзәк рәисе, 1922–1925 елларда Казакъстан краен өйрәнү җәмгыяте рәисе була.

Бу җәмәгать эшлеклеләренең икесе дә 1926 елда Бакуда уздырылган тюркологлар съездында язмачылыкны латин графикасына күчерүгә каршы чыгалар.

Аларның фәнни хезмәтләре юнәлешләрендә дә охшашлыклар күп:

– Г. Ибраһимов 1911 елда «Татар сарыфы»н әзерләп бастыра һәм шуның белән татар грамматикасы теориясенә юл сала. А. Байтурсынов 1912 елда «Оқу құралы» хезмәте белән казакъ алфавитын нигезли (бу дәреслек 1925 елга кадәр берничә мәртәбә басылып чыга), 1914–1916 елларда казакъларның нигез теленең беренче фонетикасын, морфологиясен һәм синтаксисын эшли [Байтұрсынұлы, 2013];

– милли әдәбият өлкәсенә килгәндә, Г. Ибраһимов 1914 елда «Әдәбият дәресләре»н, А. Байтурсынов 1926 елда «Әдәбиет танытқыш»ны яза [Байтұрсынұлы, 1989];

– ике галим дә туган телне укытуның яңа методикасына нигез салалар. А. Байтурсынов 1912 елда «Оқу құралы» һәм шушы өлкәгә караган берничә мәкалә яза; Г. Ибраһимов 1916 елда «Татар телен ничек укытырга?» китабын бастырып чыгара.

Сәяси карашлары буенча да бу шәхесләрдә уртак юнәлешләр аз булмый (монда максат аларның

нинди сәяси юл сайлавын күрсәтү түгел. – *Авт.*). Иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр буларак алар икесе дә милли юнәлешкә өстенлек бирәләр. Аларның бу юлдагы каршылыклары да бер үк төрле [https://ru.wikipedia.org/wiki; https://kk.wikipedia.org/wiki].

Бу язучылар икесе дә халык арасыннан күтәрелеп чыкканнар. Әсәрләрендә тасвирланган мотивларның да охшашлыгы бәхәссез. Әдипләрнең иҗат хәзинәләрен махсус рәвештә янәшә куеп өйрәнү күп төрле яңа нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирәчәк.

Казакъ язучысы, әдәбият галиме М. Ауэзовның А. Байтурсынов турындагы түбәндәге фикерләрен һич икеләнми Г. Ибраһимовка карата да әйтергә була: «Казахская школа, открытая Ахметом, родной язык, возрожденный Ахметом, гимн национализма в литературе – «Қырық мысал», «Маса», «Казах», огромный труд на благо казахского народа – все это даже если мы забудем, история не забудет. Это знает весь народ. Никто и не сомневается в истинности этого».

Г. Ибраһимов белән А. Байтурсынов язмышларын янәшә баручы күренешләр дип бәяләү һич кенә дә дөрес булмас иде. Чөнки аларның максатлары уртак. Аларны без уртак язмышлы шәхесләр дип ныклы ышаныч белән әйтә алабыз.

Г. Ибраһимовның казакълар белән рухи бәйләнешләре хакында башка мәгълүматлар да бар. Казакъларның танылган шагыйре Магжан Жумабаев Кызылжар (Петропавловск) мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Уфага китеп, «Галия» мәдрәсәсендә укый. Мәдрәсә мөгаллиме Галимҗан Ибраһимов талантлы яшь казакъ шагыйренә игътибар итә һәм Магжанга башка уку йортына китеп белем алырга, сүз сәнгате серләренә тирәнрәк үтеп керергә киңәш бирә. Г. Ибраһимов үзенең «Казак кызы» романына эпиграф итеп Магжан Жумабаевның түбәндәге юлларын сайлый:

*Кең дала, көресің ғой, ана жатқан,*
*Жібектей жасыл шөптер бетін жапқан.*
*Асқар тау, балдан тәттi сулары бар –*
*Әне, сол анам едi менi тапқан.*

Казакълар илендә А. Байтурсынов эше, аның идеяләре дәвам итә, казакъ-татар әдәби һәм мәдәни багланышларга игътибар кимеми [Ысқақов; Сәтбаева].

Хәзер сезнең игътибарыгызга А. Байтурсыновның 1928 елда «Безнең юл» журналында басылып чыккан Г. Ибраһимов турындагы мәкаләсен тәкъдим итәбез.

**Галимҗан Ибраһимов төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы**

Мәдәният юлында артда калган илнең алга чыгып, күзгә күренерлек адәмләре бармак белән генә санарлык була. Бу – бер. Икенчедән, андый адәмләрнең үз халкыннан артдырып, эшенең сәмәрәсен читкә чыгарырлыклары да аз була. Шул азларның берсе – Галимҗан Ибраһимов.

Еракда – далада яткан без – Казак туганларның күзенә Галимҗан юлдаш күгдән төшкән

бер азамат, аның эшләгән эшләре, уйлаган фикерләре татар мохитендән читкә чыгып, безгә дә арткан бер кеше. Шунлыктан аның 20 еллык фикер, тел хезмәтен искә алыб, аңа хөрмәт күрсәтеб, үз халкы туй кылыб ятканда, без дә бер-ике авыз сүз әйтүне тиешле табдык.

Иң элек шуны әйтергә кирәк: бер халык икенче халыкка төрле ягы белән якынлаша, төрле якдан бәйләнешә, ялгана, нинди генә халык булса да беренең мәдәниятендән бере файдаланыб, берендән бере үрнәк күреб, өлге алыб алга басканы мәдәният тарихындан билгеле. Шул берендән бере өлге алыб файдалану ике халык арасында тормыш ягындан, гореф-гадәт ягындан, тел ягындан якынлык булу белән дә бик нык бәйләнгән. Шундый якынлык булганда гына берендән бере файдалану җиңел була; андый якынлык булмаса, файдалану аз була.

Шул канундан төрк халыклары да котыла алмаган һәм котыла алмый да. Ләкин боларның арасы якынлыкдан «уң кул биргәнне суңысы белми» калыб, үз араларындагы йогынты сизелми кала. Мисалга безнең Казак халкын алсак – ул тирә-ягындагы халыкдан һәркайсының якынлыгына караб файдаланганы күренеб тора. Казакның тирә-ягындагы халыкның иң мәдәниятлесе нимес, андан соңгысы урыс, аның артында татар белән үзбәк тора. Казак халкы шуларның мәдәниятендән файдаланганда азындан аз алыб, күбендән күб алыб файдаланганы юк, бәлки якынлыгына караб файдаланды. Нимес мәдәниятендән Казак төрк дә алганы юк. Урыс мәдәниятендән үз ирке белән алганы – иген чәчү. Татар белән үзбәкдән алганы: үзбәк Казакка ишан бирде, татар – мөгаллим бирде.

Патша заманында Казакка мөгаллим әзерләп биргән, Казакка төрки танытыб, укырга-язарга өйрәткән татар булды. Патша хөкүмәте татар мөгаллимен Казак арасына җибәрмәскә төрле чаралар эшләсә дә, аңа карамады, татар мөгаллиме Казак эченә тулып китде.

Урыс татардан күб, аның мәдәнияте дә татардан көчле иде, учительләре нигә Казак арасына чыкмады, нигә Казакка уку-язу өйрәтмәде? Аларның Казак эченә баруына патша хөкүмәте каршы булмак түгел, баруына ярдәмләшә иде. Татар мөгаллимен Казак эчендән куыб бетерә алмыйча патша хөкүмәтенең азаблануының сәбәбе ни иде? Аның сәбәбе югарыда әйтелгән якынлык иде. Урыс белән Казакның арасында күршелекдә якынлык бар, кәсебенең төрендә якынлык бар: икесе дә иген игә. Кәсебенең төре якын булганлыкдан Казак урысдан өлге алыб иген игәргә өйрәнде. Андан башка, ни телендә, ни тормышында, ни гореф-гадәтендә якынлык булмагач, урыс учителе Казак тормышына көйләнә алмады, Казак тормышы урыс учителен күбләб үз эченә тартыб ала алмады.

Мондан ни күрәбез? Мондан шуны күрәбез: арасында якынлык бар халык берәве алга басса, башкалары да шундан өлге алыб алга омтыла икән, берсенә берсе йогынты ясый икән.

Соң әнә шул йогынты һәм якынлыкны өзмәскә нинди чаралар бар? Мәсьәлә шунда. Юлның төрле якка караб таралуы шул җирдә. Берәүләр: төрк халыкларының арасы ераклашмасын өчен теле бер булу кирәк, диләр. Теле бер булу өчен мәдәниятдән түбәнләре үз телләрен ташлаб, мәдәнияте югары булганларының телен кулланыб, шул тел белән укытыб, шул тел белән әдәбият тудырсын диләр (*Атаклы Гаспринский 30 ел буена шул фикерне чәчде. Җәмал Вәлидидә дә шундый уй бар иде («Татар әдәбиятының барышы» дигән китабын карагыз). Ләкин боларның чәчкән фикере һич бер җимеш бирмәде. Казак үз алдына әдәбият тудырды. Башкорт, кыргыз кебек саны аз халык та совет хөкүмәте аркасында үз телен тергезеп, үз әдәбиятын аякка бастырды*). Берәүләре төрк халыкларының телләрен берләштерү, әүвәле мөмкин була торган эш түгел; икенчедән, мөмкин булганда да аңа күб көч белән, күб эш кирәк, ул эш төрк халкының кулындан килми; максат төрк халыкларының барын да бер телдә сөйләштерү түгел, берендән бере өлге алыб, мәдәният юлында берендән бере файдаланырлык итү, аның өчен телен берләштермичә генә, беренең әдәбиятын икенчесе аңларлык булса җитә, диделәр.

Менә шул мәсьәләдә Галимҗан юлдаш төрк уйчыларының кай тарафында торып Казак күзенә күренгәнен әйтеп үтмәкче булам.

1. Без – Казак халкы саф Казак телендә матбугат тудырыб, әдәбиятыбызны тергезгәндә, балаларыбызны үз телебездә укыта башлаганда татар туганнарыбызның ул вакытда алдагы сафдагыларының күбесе бу эшкә каршы булды. Ул вакытда татарча гәзит-журналларда безгә каршы язылган фикерләргә урын бирелде. Шул вакытда безнең юлыбызның турылыгын әйтеб, безнең эшебезне кулалаган татар азаматларындан Галимҗан Ибраһимов белән Хәсән Гали булды.

2. Беренче тюркология корылтаенда ясаган доклады буенча Галимҗан юлдашны Казакларның тануы тагы башкарак булды. Мәсьәлә – төрк халыкларының хәзерге кулланмакда булган язуы белән хәреф мәсьәләсе иде. Галимҗан: «Телне беректерү кыен эш, ул кулыбыздан килми; мәдәният казнасы булган әдәбиятдан төрк халыклары уртак файдалану өчен тел бер булу кирәк иде, ләкин алай түгел, тел башка-башка. Аны беректерү мөмкин дә түгел. Шулай булгач, төрки әдәбиятны төрк халыклары бары да файдаланырлык мөлек, уртак казна итү өчен башка чара эзләргә, башка әмәл табарга кирәк», – дип чыкды.

Ул әмәл, Галимҗанның фикеренчә, 1) төрк телләрендәге барына уртак нәрсәләрне дөресләп, уртак файдалана белүдә, 2) төрк халыклары үзара аңлашыб күгезүдә (?) булачак.

Төрк телләрендә, бер ягындан, берендән берен аера торган хосусиятләр булса, икенче ягындан, беректерә торган хосусиятләр дә бар, ди Галимҗан. Мәсәлән, фонетика законы барына да бер; морфология ягындан сүзләрнең тамырындагы

авазларда уртаклык бар. Шуларны тәртибкә салыб, уртак файдаланырлык итәргә кирәк. Алай итәр өчен Галимҗан шундый нигезләрне тәкъдим итә:

А) имляда тик фонетика нигезенә таянмыйча, сүзләрнең тууышы нигезенә дә карарга кирәк;

Б) имляны шивәләргә бәйләүдән качу, бәйләүчеләр белән көрәшү;

П) аваз тамгалары (хәрефләр) бер булу, яңа тамга алганда бергә аңлашыб алу;

Т) яңа фән атамаларын алганда уртак куллануга ярарлыкларын алу;

Ж) шуларның барын тел корамалары аркылы үткәзү.

Төрк әдәбияты төрк халыкларының уртасындагы уртак казна булуы турысында Галимҗанның ничек уйланыб, нинди чаралар эзләгәне мондан ачык күренеб тора.

Менә шул әйткән нәрсәләр бары да Галимҗан юлдашны татар чигендән чыгарыб, киңерәк мәйданда йөзә торган гомумән төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы итеб таныта торган эшләр. Галимҗан юлдашны без шулай таныйбыз. «Юлдаш» дигән сүзне мин бу җирдә гадәтдә нәзакәтән әйтелә торган юлдаш мәгънәсендә алмыйм, чын мәгънәсе белән юлдаш диб алам. Чөнки йөрешебез башка булса да, юлыбыз бер. Юлыбызда төрле сикәлтәләр булыр, кай урында төшеб дә калырбыз, эш анда түгел, эш ниятдә. Ниятебез дөрес булса, юлның сикәлтәсендән күб зарар булмас.

Сүзнең азагында Галимҗан юлдашка теләгебез озын гомер белән саулык. Гомере булса, ниятенә җитүенә иманыбыз камил.

Әхмәт Байтурсын улы.
24/28 – Кызыл Урда.

**Әдәбият**

*Байтурсынов А.* Галимҗан Ибраһимов төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы // Безнең юл: Татарстан җөмһүрияте Мәгариф халык комиссариаты органы. 1928. № 2. Б. 17–18.

*Байтұрсынұлы А.* Қазақ тіл білімінің мәселелері. Алматы: Абзал-Ай, 2013. 640 б.

*Байтұрсынұлы А.* Әдебиет танытқыш // Байтұрсынұлы А. Шығармалары. Алматы: Жазушы, 1989. Б. 137–298.

Большая советская энциклопедия: в 30 т. 3-е изд. М., 1969–1978. Т. 9. С. 621.

*Сәтбаева Ш.* Әдеби байланыстар. Алматы: Жазушы, 1974. 215 б.

*Ысқақов Б.Ы.* Қазақ-татар әдеби байланысы. Алматы: Ғылым, 1976. 175 б.

https://ru.wikipedia.org/wiki

https://kk.wikipedia.org/wiki

***Жакупов Жантас Алтай улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия милли университеты*
*профессоры (Астана, Казакъстан)*